ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.08.2019 Олы Кайбыч авылы № 387

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен башкарганда тикшерүләр үткәрү Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең 2018 елның 3 августында чыккан 340-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым канунчылык актларына үзгәрешләр кертү турында» Законына таянып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 29.03.2019 чыккан 151карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен башкарганда тикшерүләр үткәрү Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3.5. пунктын түбәндәге эчтәлекле 3.5.6. подпункты белән тулыландырырга:

«3.5.6. муниципаль җир контроле чикләрендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органы вазыйфаи заты тарафыннан капиталь төзелеш объекты мондый объект урнаштырылу рөхсәт ителмәгән җир кишәрлегендә урнаштырылу факты ачыкланган очракта, күрсәтелгән зат тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча әлеге җир кишәрлеге урнашкан җирлекнең, шәһәр округының җирле үзидарә органына яки мондый җир кишәрлеге җирлекара территориягә урнашкан булса, муниципаль район җирле үзидарә органына үз ихтияры белән төзелгән корылма турында әлеге фактны дәлилләүче документларны теркәп хәбәрнамә юллый. Үз ихтияры белән төзелгән корылма турында хәбәрнамә формасы шәһәр төзелеше турында канунчылык нигезендә билгеләнә. Күрсәтелгән тикшерү нәтиҗәләре җир кишәрлеге хокукларына ия зат тарафыннан суд тәртибендә шикаять ителә ала.»

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җир һәм милек мөнәсәбәтләре Палатасы Рәисе О.Д.Макаровка йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров